ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

# IX СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫН ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫН ҮТҮГӘ ӘЗЕРЛӘҮ

(ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ)

КАЗАН
2016

ББК 74.268.1 Тат
Һ 16

Автор-төзүчеләр:
Г.В.Һадиева
Л.Г. Гыйләҗева

IX сыйныф укучыларын татар теленнән Бердәм республика тестын үтүгә әзерләү (текст белән эшләү методикасы) / авт.-төз.: Г.В.Һадиева, Л.Г. Гыйләҗева. – Казан, ТРМҮИ, 2016. – 34 б.

Чыгарылыш сыйныф укучылары, татар теле һәм әдәбияты укытучылары бердәм республика тесты белән яхшы таныш, шулай да, язма эш өлеше – бүгенге көндә дә сораулар тудыра торган өлеш. Бердәм республика тесты кысаларында укучылар **21 нче код** буенча – изложение һәм сочинение, **22 нче код буенча** сочинение язарга тиешләр. Бирелгән кулланмада имтиханда текст белән эшләү методикасына (изложение һәм сочинение) урын бирелә. Хезмәттә изложение һәм сочинение язу эзлеклелеге һәм аны язу үзенчәлекләре яктыртыла, сочинение үрнәкләре бирелә.

**© ТРМҮИ, 2016**

# ИЗЛОЖЕНИЕ ЯЗУ ТЕХНИКАСЫ

Аудиоязмадан текстны **беренче тапкыр тыңлаганда,** аның эчтәлеген һәм авторның фикерен аңларга тырышыгыз. Тыңлау барышында текст артыннан ук ниндидер язмалар теркәп барырга киңәш итмибез. Укучылар бар көчләрен “нәрсә дә булса” язып алуга сарыф итеп, ишеткәннәрен рәттән язып бара башлыйлар. Шул ук вакытта эчтәлекнең иң мөһим өлеше читтә калырга мөмкин. Текстны тыңлаганда аның төп темасы, микротемалары, идеясе һәм мәгънәви кисәкләрнең үзара бәйләнеше турында фикер йөртү күпкә нәтиҗәлерәк булачак.

Текстны **икенче тапкыр тыңлаган вакытта** язмаларны теркәп бару күпкә отышлырак. Укучының нәрсә һәм ничек язуы ирекле. Шулай да, ялгызлык исемнәре, даталар, туры сөйләм яки диалог һәм терәк сүзләр язылырга тиеш. Язмалар арасында буш урын калдыру ахырдан өстәмәләр кертергә мөмкинлек бирәчәк.

**Текстны аңларга бирелгән вакытта** (текстны беренче тапкыр тыңлаганнан соң) абзацларның эзлеклелеген (авторның фикер йөртешен, тасвирлауларның бирелешен яки вакыйгалар хронологиясен) билгеләп куярга кирәк. Бу сезгә дөрес итеп план төзергә һәм микротемаларны билгеләргә мөмкинлек бирәчәк.

Икенче тапкыр тыңлаганнан соң, язмалар арасындагы буш урыннарны тутырып, текстны хәтерегездә яңартыгыз. Изложение тексты өстендә эшне бетергәч кенә компрессия ысулларына күчәргә мөмкин.

Тыңлау барышында ук язмалар алып барып, **изложение өстендә эшләүнең икенче юлын** сайлап була.

Беренче тыңлау барышында мөһим сүзләр, гыйбарәләрне теркәү бара. Мәгълүматны яңадан өстәү мөмкинлеге калсын өчен, җөмләләр арасында буш урын калдырырга кирәк. Мәгънәви кисәкләрне шартлы билге белән (**Z**) билгеләп чыгыгыз. Икенче тапкыр тыңлаганда, абзацларга бүленешнең дөреслегенә игътибар итәргә онытмагыз.

Гадәттә, текстны икенче тапкыр тыңлау барышында якынча план төзелә яки язмаларга өстәмәләр кертелә. Бигрәк тә, текстның идеясен саклауда мөһим булган дата, өземтә, ялгызлык исемнәренә, таныш булмаган географик атамаларга игътибарлы булыгыз.

***Ишетеп кабул ителә торган текст белән эшләү эзлеклелеге:***

1. Башлангыч текстны тыңлагыз.
2. Текстның темасын (Текст нәрсә турында?) һәм идеясен (Автор нәрсә әйтергә теләгән?) билгеләгез.
3. Вакыйгалар һәм фикерләрнең эзлеклелеген, текст төзелешенең үзенчәлеген билгеләгез:
   - хикәяләүдә – вакыйгаларның башланып китүе, барышы, кульминациясе, бетеме;
   - тасвирлауда – сөйләм предметы һәм аның төп билгеләре;
   - фикерләүдә – гомуми фикерләр, дәлилләр, нәтиҗә.
4. Һәр өлешнең микротемаларын аерып, текстның тулы планын төзегез.

5. Текстка туры килә торган кыскарту (компрессия) алымнарын сайлагыз.

6. Әлеге алымнарны кулланып, төп мәгълүматны һәм барлык микротемаларны саклап, текстны кыскартыгыз.

7. Изложениедә өлешләр арасында мәгънәви һәм грамматик бәйләнешне һәм авторның фикере сакланылуын тикшерегез.

8. Изложениене языгыз.

9. Үзегезнең текстыгызны кабаттан укыгыз һәм андагы сүзләрне санагыз (алар **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш). Әгәр дә күләме аз булса, киңәйтеп була торган өлешне билгеләгез.

10. Изложениенең эчтәлеген укыганнан соң, аның грамматик, сөйләм, орфографик, пунктуацион хаталарның булу-булмавыннан чыгып, текстны җентекләп тикшерегез.

***Планны ничек төзергә?***

Еш кына укучылар план урынына терәк схема кулланалар. Мәгълүматны теркәүнең әлеге ысулын, әлбәттә, кулланырга мөмкин. Иң нәтиҗәлесе исә – битне вертикаль сызык белән икегә бүлеп, бер ягына – беренче тапкыр тыңлаганда истә калган терәк сүзләрне, икенчесенә – өстәмәләрне, гыйбарәләрне һәм билгеле бер сүзләрне язу.

Түбәндәге текст буенча терәк конспект һәм план төзергә тәкъдим итәбез.

«Бала үз язмышы белән туа», диләр. Язмышның да бик мөһим өлеше – әти-әниләрдән, бабай-әбиләрдән яшь буынга биреп калдырылган генетик мирастыр.

Югыйсә, әтисен бөтенләй күрмәгән, өч яшендә әнисез дә, туганнарсыз да калып, үз гомерендә җиде ят хатын-кызга «әни» дип эндәшергә мәҗбүр булган Тукаебыз, татар халкының өмете, сөекле улы булып танылыр өчен, үзенә гаҗәеп зур яшәү энергиясе өстәрлек көчне кайдан алыр иде?

Әлбәттә, һәр баланың яшәгән мохите, уку, эшләү шартлары, аның тырышлыгы, ниятләренең изгелеге, хыялларының матурлыгы, омтылышларының бөеклеге, һичшиксез, язмышына да зур йогынты ясыйдыр. Әйтик, Габдуллабыз Кырлайда, гомерендә беренче мәртәбә гаилә җылысы күргән Сәгъди абзыйларда калган булса... Нинди куаныч, янәшәсендәге шәфкатьле, кайгыртучан кешеләр Габдуллабызны да Җаек (Уральск) шәһәренә алдырып, язмышында бөтенләй башка мөмкинлекләр ачалар: танылган «Мотыйгыя» мәдрәсәсе һәм аның киң карашлы мөдире, урысча да укып алу, типографиядә эшләү, редакцияләр белән хезмәттәшлек... Инде ул «өметле» шагыйрь булып танылып Казаныбызга кайта һәм халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга әверелә. Ә Казанга кайтмаган булса?..

Димәк, һәр кеше үз язмышын булдыруда үзе төп рольне башкара. Аның сыйфаты тормыш юлында кемнәр очраудан һәм аларнын карашларыннан, ярдәм күрсәтә алырлык теләк-гамәлләреннән тора. Илдәге сәясәт тә шул ил кешеләре язмышында үз тәэсирен дә калдырганын онытмаска кирәктер.

(А. Зыятдинов буенча)

Таблицада терәк конспект һәм план пунктлары күрсәтелгән.

| Терәк конспект | План |
|---|---|
| 1. Язмыш; генетик мирас; ятим Тукай.<br>2. Мохитнең язмышка йогынтысы – Кырлай (Сәгъди абый), Җаек – танылган «Мотыйгыя» мәдрәсәсе – шагыйрь булып Казанга кайту.<br>3. Төп роль; тормыш юлында очраучылар, илдәге сәясәт. | 1. Бала үз язмышы белән туа.<br>2. Яшәгән мохите, уку, эшләү шартлары, кешенең тырышлыгы, аның язмышына да йогынты ясый.<br>3. Һәр кеше үз язмышында үзе төп рольне башкара. |

Абзацның беренче җөмләсендә үк автор: *“Бала үз язмышы белән туа,”* – дигән тезис бирә. Башламда фикерләүнең үсеше өчен мөһим булган уй-фикер формалаштырыла.

Аннан соң төп өлеш – теманың, фикернең үсеше башлана: *яшәгән мохит, уку-эшләү шартлары, тырышлык, изге ниятләре, хыяллар да, бала язмышына зур йогынты ясый.*

Соңгы өлештә фикер йөртү нигезендә нәтиҗә ясала: *һәр кешенең язмышы үз кулларында.*

Алда әйтелгәннәрне искә төшереп һәм кайбер теоретик мәгълүматларны өстәп, конкрет текст нигезендә кыска изложение язу эшчәнлеген оештырып карыйк.

## ***Матурлык***

*Аның чәчәк бакчасы авылда бер иде. Тәлинкә-тәлинкә дәлияләр, куе кызыл, сары, шәмәхә башларын ия төшеп, вәкарь белән генә утыралар. Җилбәзәк үрмә гөлләр иртә таңда, кичке салкында зәңгәр күзләрен кысышып өй кыегына йөгерәләр. Юл буена тезелгән кашкарыйлар, лаләләр каршы ала сине. Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым.*

*Хуҗа хатын кайсы чәчәкне кайдан китерткән, ничек утырткан, ничек тәрбияләгән, үстергән, шуларны тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа кеше өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән. Хатынның йөзе кинәт бозылды. Мине һәм чәчәкләрне онытып, ире янына йөгереп килде, бәйләргә дип әзерләгән бауны аның кулыннан тартып алды.*

*– Матурлык дигән нәрсә бар бит. Ма-тур-лык! Аңлыйсыңмы син шуны?! – дип кычкырды ул калтыранып.*

*– Узган ел да таралып төште бит, кил алайса, уйлашыйк, ничегрәк итсәң яхшы булыр, – диде хуҗа кеше юаш кына тавыш белән.*

*– Кит, кит, тотынма, ичмасам!*

*Хуҗа, әллә үзенең булдыксызлыгыннан, әллә хатынының дуамаллыгыннан уңайсызланып, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады.*

*Минем өчен бакчаның яме сүнде. Әле генә кояш көлеп торган матурлык дөньясына кара болыт килеп ятты да чәчәкләрнең ямен алып, барына да тонык, төссез, салкын җәймәсен япты.* (187 сүз)

*(Л.Ихсанова)*

***Текстны беренче тапкыр уку***

**1 нче адым** – текстның темасын билгеләү. Бу этапта “Текст нәрсә турында?” соравына җавап эзләгез.

Теманы:

**– текстның башламыннан;**

**– текстның төп фикерен ачарга ярдәм итә торган сүзләрдән;**

**– геройларның эш-хәрәкәтләре яки фикер йөртүләреннән;**

**– текстның исеменнән** билгеләп була.

Әлеге ***текстның темасы*** – матурлык, ул исемдә үк чагылыш тапкан.

**2 нче адым** – текстның идеясен билгеләү. Тексттагы матурлык темасы аркылы “Автор нәрсә әйтергә тели? Нинди фикер үткәрә?” дигән сорауга җавап эзләгез, ягъни текстның идеясен билгеләгез.

***Идея*** − әсәрдәге конкрет вакыйгалар һәм җанлы образлар сурәтләнешендә бирелгән төп фикер.

Идеяне формалаштырырга түбәндәгеләр ярдәм итә:

– текстның тональлеге;

– текстны укыганнан соң туган уй-хисләр;

– авторның геройларга, вакыйгаларга мөнәсәбәте;

– текстта төп фикерне турыдан-туры яки өлешчә формалаштыра торган тезис.

***Текстның идеясе*** – матурлыкның, беренче чиратта, кешеләрнең күңелендә, уйларында, эш-гамәлләрендә чагылуында, ягъни эчке һәм тышкы матурлыкның гармониядә булуында.

**3 нче адым** – текстның структурасын билгеләү. Бу этапта текстның композицион өлешләрен билгеләгез һәм аларның эчтәлеген тезис формасында язып куегыз.

Текстның төп композицион өлешләре булып **кереш, төп өлеш** һәм **йомгак** тора.

**Текстның композицион өлешләргә бүленеше**

***Кереш:***

*Аның чәчәк бакчасы авылда бер иде. Тәлинкә-тәлинкә дәлияләр, куе кызыл, сары, шәмәхә башларын ия төшеп, вәкарь белән генә утыралар. Җилбәзәк үрмә гөлләр иртә таңда, кичке салкында зәңгәр күзләрен кысышып өй кыегына йөгерәләр. Юл буена тезелгән кашкарыйлар, лаләләр каршы ала сине. Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым.*

Кереш өлешнең төп фикере – *"Аның чәчәк бакчасы авылда бер иде"* җөмләсендә бирелгән.

***Төп өлеш:***

*Хуҗа хатын кайсы чәчәкне кайдан китерткән, ничек утырткан, ничек тәрбияләгән, үстергән, шуларны тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа кеше өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән. Хатынның йөзе кинәт бозылды. Мине һәм чәчәкләрне онытып, ире янына йөгереп килде, бәйләргә дип әзерләгән бауны аның кулыннан тартып алды.*

*– Матурлык дигән нәрсә бар бит. Ма-тур-лык! Аңлыйсыңмы син шуны?! –дип кычкырды ул калтыранып.*

*– Узган ел да таралып төште бит, кил алайса, уйлашыйк, ничегрәк итсәң яхшы булыр, – диде хуҗа кеше юаш кына тавыш белән.*

*– Кит, кит, тотынма, ичмасам!*

*Хуҗа, әллә үзенең булдыксызлыгыннан, әллә хатынының дуамаллыгыннан уңайсызланып, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады.*

Төп өлешнең фикере *“Хуҗа, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады”* җөмләсендә чагыла.

***Йомгак:***

*Минем өчен бакчаның яме сүнде. Әле генә кояш көлеп торган матурлык дөньясына кара болыт килеп ятты да чәчәкләрнең ямен алып, барына да тонык, төссез, салкын җәймәсен япты.*

“*Минем өчен бакчаның яме сүнде*” җөмләсеннән йомгакның төп фикерен аңлап була.

Шулай итеп, текстны беренче тапкыр тыңлаганнан соң, син изложение текстының темасын, идеясен, композицион өлешләрен һәм һәрбер өлешкә салынган төп фикерне билгеләдең.

***Текстны икенче тапкыр уку***

Текстны икенче тапкыр тыңлау барышында абзацлар санын билгеләргә кирәк. Гадәттә, текстны абзацларга бүлгәндә сораулар туа.

Абзац (“кызыл юл”) язуда аерылып тора. Ә сөйләмдә абзацны *ишетеп* буламы? Әлбәттә! Укыганда абзац алдыннан, башка җөмләләр белән чагыштырганда, озынрак пауза ясала. Текстны яздырганда, диктор әлеге шартка туры китереп укый. Димәк, тексттагы абзацларны интонацион паузалар саны буенча билгеләп була.

Абзац (микротекст) билгеле бер төзелешкә ия. Абзацтагы җөмләләрнең вазифалары да төрле. Аларның урнаштырылуы түбәндәге схемага буйсына: *башлам, фикер үстерелеше, бетем*. Абзацның мөһим җөмләсе, гадәттә, текстның башында яки ахырында була.

Абзацлар нигезендә текстның микротемалары билгеләнә. ***Микротема*** – бер фикер белән бәйләнгән, берничә мөстәкыйль җөмләнең эчтәлеген бирә торган кисәк. Абзац – микротеманың күрсәткече, шуңа күрә изложение текстын укыганда интонацион паузаларга игътибарлы булыгыз! Әйтеп үткәнебезчә, текстта абзацлар зур интонацион паузалар санынча була.

Димәк, абзацлар санын мәгънәви кисәкләрдән һәм интонациядән чыгып билгеләп була.

Тексттагы абзацлар саны белән микротемалар тәңгәл килергә тиешме? Һәрбер абзацның микротемасы булу мәҗбүриме? Кыска изложениедә барлык микротемалар да сакланырга тиеш, ә абзацлар саны тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Бер абзацта, кагыйдә буларак, бары бер генә микротема була, ләкин кайбер очракта 2-3 абзац бер микротемага берләшергә мөмкин.

“Матурлык” хикәясендә 3 микротеманы аерып чыгарырга мөмкин. Беренче микротемага беренче абзац туры килә. Әлеге өзек текстның кереш өлеше белән тәңгәл килә. Микротеманы, план язгандагы кебек, үз сүзләрең белән дә яки тексттан өземтә итеп тә алырга мөмкин. Беренче микротемага исем бирәбез: *“Анының чәчәк бакчасы авылда бер иде”.*

Икенче микротемага 6 – 13 җөмләләр карый, ул күләме ягыннан кечкенә булган 5 абзацны берләштерә һәм

композицион яктан төп өлешкә туры килә. Микротеманы түбәндәгечә атарга мөмкин: *“Хуҗа, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады.”*

Өченче микротема 14 – 15 җөмләләрдән гыйбарәт һәм текстның йомгагына туры килә. Микротеманың мәгънәсе *“Минем өчен бакчаның яме сүнде”* җөмләсендә чагыла.

Димәк, текстны икенче тапкыр укыганда, син абзацларны һәм микротемаларны билгеләп, караламага язып куярга тиешсең. Тәртип буенча язылган микротемалар изложениенең планы да булып тора. Мәсәлән,

| | |
|---|---|
| **1 нче микротема** | Аның чәчәк бакчасы авылда бер иде. |
| **2 нче микротема** | Хуҗа, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады. |
| **3 нче микротема** | Минем өчен бакчаның яме сүнде. |

**Кыска изложениенең таләпләре:**

Кыска изложение өстендә эшләгәндә, төп (беренчел) һәм өстәмә (икенчел) мәгълүматны аерып чыгара белү зарур. Төп мәгълүмат – текстның идеясен һәм темасын билгеләүче җөмләләр җыелмасы. Өстәмә мәгълүмат исә предмет-күренешләрне ачыклап килүче берәмлекләрне, детальләрне үз эченә ала. Бу кисәкләрне кыскартырга яки бөтенләй төшереп калдырырга мөмкин.

Алга таба, компрессия алымнарын кулланып, башлангыч текстны кыскарту эшенә тукталырбыз. Башта компрессия алымнарын бер-берсенә бәйләнмәгән аерым җөмләләр нигезендә карарбыз, соңыннан “Матурлык” текстына әйләнеп кайтырбыз.

## Алмаштыру

<table>
<tr><th colspan="2">Тиңдәш кисәкләрне гомумиләштерүче сүзләр белән алмаштыру</th></tr>
<tr><td>Башлангыч җөмлә<br>Иртәдән башлап кичкә чаклы балта һәм пычкы, китмән һәм көрәк кулдан төшмәде.<br>(Ш. Камал)</td><td>Компрессия алымы кулланылган җөмлә<br>Көнозын кулыннан эш кораллары төшмәде.</td></tr>
<tr><th colspan="2">Тиңдәш кисәкләрне гомумиләштерүче сүз белән алмаштыру</th></tr>
<tr><td>Әкиятне зурлар да, кечкенәләр дә, көчлеләр дә, көчсезләр дә, усаллар да усал булмаганнар да яраталар.</td><td>Әкиятне бөтен кеше ярата.</td></tr>
<tr><th colspan="2">Туры сөйләмне кыек сөйләм белән алмаштыру</th></tr>
<tr><td>Әнисе аның чәчләреннән сыйпап: “Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт”, –<br>дигән, һәм йотлыгып суны эчә башлаган. (Ф.Яруллин)</td><td>Әнисе аңа рәхмәт әйтеп, йотлыгып суны эчә башлаган.</td></tr>
<tr><th colspan="2">Җөмләне яки аның өлешләрен күрсәтү алмашлыгы белән алмаштыру</th></tr>
<tr><td>Ни өчен ул тору урынын еш алыштырган? Инде ияләшеп беткән җирдән аерылып, таныш булмаган җиргә, аның кешеләренә ияләшергә, яңа эш урынын эзләргә аны нәрсә этәрде икән?</td><td>Ни өчен ул тору урынын еш алыштырган? Моңа аны нәрсә этәрде икән?</td></tr>
</table>

## Төшереп калдыру

<table>
<tr><td colspan="2">Өстәмә мәгълүматны, детальләрне төшереп калдыру</td></tr>
<tr><td>Ул аны бөтен җирдән эзләп карады: бүлмәләрне барлап чыкты, бакчадан карады, күршеләргә кереп чыкты.</td><td>Ул аны бөтен җирдән эзләп карады.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Мәгънә бөтенлегенә зыян итми торган өзекне төшереп калдыру</td></tr>
<tr><td>Кайвакыт ул эшен туктатырга да, ярты юлда калдырырга да күп сорамый.</td><td>Кайвакыт ул эшен туктатырга да күп сорамый.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Кабатлауларны төшереп калдыру</td></tr>
<tr><td>Аларның булган Ибрай исемле бик акыллы, бик зирәк, бик тапкыр бер уллары. (Татар халык әкиятеннән)</td><td>Аларның булган Ибрай исемле бик акыллы, зирәк, тапкыр бер уллары.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Риторик сорауларны төшереп калдыру</td></tr>
<tr><td>Авылыгызның нинди урында утыруына игътибар иткәнегез бармы? Ә бит безнең бабаларыбыз теләсә кайда авыл салмаганнар. Авыл булып утыру өчен, якында гына урманы да, болыны да, инеше дә булган, салкын чишмә чыга торган җайлы калкулыклар сайлаганнар. (Г.Бәширов)</td><td>Безнең бабаларыбыз теләсә кайда авыл салмаганнар. Авыл булып утыру өчен, якында гына урманы да, болыны да, инеше дә булган, салкын чишмә чыга торган җайлы калкулыклар сайлаганнар.</td></tr>
</table>

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, автор идеясен аңларга ярдәм итә торган детальләрне, төп фикерне ачу яки дәлилләү өчен кулланылган кисәкләрне ***төшереп калдырырга ярамый!*** Мәсәлән, аерымланган рәвеш хәлен төшереп калдыру-калдырмау текстка карап хәл ителергә тиеш. *Болар бар да **ялгыз** Маша өчен, **йорт байлыгы гына булмыйча**, күңелен юаткан гаилә дә иде.*

## Берләштерү яки гомумиләштерү

| **Ике (яки берничә) гади җөмләне кушма җөмләгә берләштерү** | |
|---|---|
| *Башлангыч җөмлә*<br><br>Исемгә бай ул төнбоек. Ак лалә дә ул. Су гөлчәчәге дә ул. Хәтта нимфея дә. Берсеннән-берсе матур исемнәр! | *Компрессия алымы кулланылган җөмлә*<br>Төнбоек матур исемнәргә бай: лалә, су гөлчәчәге, нимфея! |

## “Матурлык” текстын компрессияләү алымнары белән кыскартуга мисаллар

| **Ике (яки берничә) гади җөмләне кушма җөмләгә берләштерү** | |
|---|---|
| *Башлангыч җөмлә*<br><br>Тәлинкә-тәлинкә дәлияләр, куе кызыл, сары, шәмәхә башларын ия төшеп, вәкарь белән генә | *Компрессия алымы кулланылган җөмлә*<br>Монда дәлияләр, үрмә гөлләр, кашкарыйлар, лаләләр матур гына үсеп |

| | |
|---|---|
| утыралар. Җилбәзәк үрмә гөлләр иртә таңда, кичке салкында зәңгәр күзләрен кысышып өй кыегына йөгерәләр. Юл буена тезелгән кашкарыйлар, лаләләр каршы ала сине. | утыралар. |
| **Җөмләнең икенче дәрәҗәдәге мәгълүматын кыскарту** | |
| Әле генә кояш көлеп торган матурлык дөньясына кара болыт килеп ятты да чәчәкләрнең ямен алып, барына да тонык, төссез, салкын җәймәсен япты. | Әле генә кояш көлеп торган матурлык дөньясын кара болыт каплады. |
| **Сүзтезмәне сүз белән алмаштыру** | |
| Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. | Күптәннән шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. |
| **Фигыль формаларын алмаштыру** | |
| Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. | Күптәннән шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килә иде, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. |
| **Детальләрне төшереп калдыру** | |
| Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын якыннанрак күрәсем килеп тора идем, бер көнне | Күпме вакытлар шул матурлык дөньясын күрәсем килеп тора идем, |

| | |
|---|---|
| бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. | бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым. |
| Мине һәм чәчәкләрне онытып, ире янына йөгереп килде, бәйләргә дип әзерләгән бауны аның кулыннан тартып алды. | Мине һәм чәчәкләрне онытып, ире янына йөгереп килде һәм кулыннан бауны тартып алды. |
| Хуҗа хатын кайсы чәчәкне кайдан китерткән, ничек утырткан, ничек тәрбияләгән, үстергән, шуларны тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа кеше өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән. | Хуҗа хатын кайсы чәчәкне кайдан китерткән, ничек утырткан, ничек тәрбияләгән, үстергән, шуларны тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән. |
| **Мәгънә бөтенлегенә зыян итми торган өзекне төшереп калдыру** | |
| Хуҗа хатын кайсы чәчәкне кайдан китерткән, ничек утырткан, ничек тәрбияләгән, үстергән, шуларны тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа кеше өй түрендә таралып утырган чалма | Хуҗа хатын һәрбер чәчәк турында тәмләп сөйли башлаган иде, картына күзе төште: хуҗа кеше өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән. |

| | |
|---|---|
| чәчәкләрне җыеп бәйләргә йөри икән.<br><br>Хуҗа, әллә үзенең булдыксызлыгыннан, әллә хатынының дуамаллыгыннан уңайсызланып, миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады. | <br><br><br>Ул миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады. |
| **Туры сөйләмне кыек сөйләм белән алыштыру** | |
| – Матурлык дигән нәрсә бар бит. Ма-тур-лык! Аңлыйсыңмы син шуны?! – дип кычкырды ул калтыранып.<br>– Узган ел да таралып төште бит, кил алайса, уйлашыйк, ничегрәк итсәң яхшы булыр, – диде хуҗа кеше юаш кына тавыш белән.<br>– Кит, кит, тотынма, ичмасам! | Ул ирен матурлык төшенчәсен аңламавында гаепләп, калтыранып кычкырды. Хуҗа юаш тавыш белән генә хатынын киңәшләшергә чакырды, ләкин җавапка “Кит, тотынма!” дигән сүзләр генә ишетте. |

Шул рәвешле, компрессиянең төрле ысулларын кулланганнан соң, текст түбәндәге форманы ала.

| |
|---|
| Анының чәчәк бакчасы авылда бер иде. Монда дәлияләр, үрмә гөлләр, кашкарыйлар, лаләләр матур гына үсеп утыралар. Күптәннән шул матурлык дөньясын күрәсем килә иде, бер көнне бакчада хуҗаларын очратып рөхсәт сорадым.<br>Хуҗа хатын һәрбер чәчәк турында тәмләп сөйли |

башлаган иде, өй түрендә таралып утырган чалма чәчәкләрне бәйләргә йөргән картын күрде. Хатынның йөзе кинәт бозылды. Мине һәм чәчәкләрне онытып, ире янына йөгереп килде һәм кулыннан бауны тартып алды. Ул ирен матурлык төшенчәсен аңламавында гаепләп, калтыранып кычкырды.

Хуҗа хатынын киңәшләшергә чакырды, ләкин җавапка “Кит, тотынма!” дигән сүзләр генә ишетте. Ул миңа елмаеп карарга тырышты, әмма булдыра алмады.

Минем өчен бакчаның яме сүнде. Әле генә кояш көлеп торган матурлык дөньясын кара болыт килеп каплады.
*(110 сүз)*

# СОЧИНЕНИЕ
# ЯЗУ БУЕНЧА МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

Исегезгә төшерәбез, икенче өлеш (22 код) яки өченче өлеш (21 код) бирелгән темадан читкә китмичә, үз фикереңне белдереп, иҗади эш башкаруны таләп итә. Шулай да, үзеңнең җавабыңны "килешәм-килешмим" дигән бәяләмә бирү белән генә чикләргә ярамый. Имтихан эшенең бу өлешендә мини-сочинение язудагы шәхси осталык исәпкә алына. Әлеге этапта укучылардан фикерләү камиллеген күрсәтә белү сорала.

Укучының язма эше – тулы текст, шуңа күрә ул текстның барлык билгеләрен үзендә тупларга тиеш. Сочинение тексты мәгънәви кисәкләрдән чыгып, абзацларга бүленә. Абзацларның төп җөмләләре текстның нигезен тәшкил итәләр. Әгәр барысы да дөрес эшләнсә, бу җөмләләрне укыгач, бәйләнешле текст килеп чыгарга тиеш. Абзацларның булмавы, яки, киресенчә, текстның абзацларга артык ваклануы сочинение өчен баллның түбәнәюенә китерә.

Сочинение текстын нинди критерийлар буенча бәяләвен алдан белгән очракта эшнең сыйфаты яхшырак булачак. Шуңа күрә ул критерийлар белән танышу гына җитми, экспертларның имтихан эшендә нәрсә күрергә теләвен төгәл белергә кирәк.

**Истә тотыгыз!!!** 2016 нче елгы бердәм республика тесты кысаларында укылган текстны файдаланып, 2 биремнең бары тик берсен генә сайлап алып, язма эшне башкаруны күздә тота. Язма эшнең күләме түбәндәгечә: ул

50 сүздән дә (21) яки 100 сүздән дә (22 код) ким булмаска тиеш.

Бирелгән текст буенча сочинение язу әлеге тексттан алынган фрагментның мәгънәсен аңлатуны күздә тота. Әлеге төр сочинениенең төп эчтәлеге – тексттагы мәгълүматны анализлау.

2016 нче елгы рус мәктәпләренең татар төркемнәре өчен имтихан эшендә ул түбәндәге формада бирелгән.

**21.1. Безнең беренче ризыгыбыз булган икмәккә кеше игътибары, кеше мәхәббәте кирәк. Бары шулчакта гына муллыкка ирешеп булачак.** Текст ахырында китерелгән бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатып, сочинение языгыз.

Укылган тексттан фикерегезне раслый торган 2 дәлил китерегез. Мисалларны биргәндә, кирәкле җөмләләрне языгыз яисә аларның номерын күрсәтегез.

Сочинениенең күләме **100 сүздән** дә ким булмаска тиеш. Сочинениене чиста һәм тanырлык итеп языгыз.

Иң элек укучылар өчен сочинение язуның эзлеклелеген билгелибез.

1. Текстны ашыкмыйча, игътибар белән укыгыз.
2. Биремне укыгыз һәм биремдә күрсәтелгән җөмләләр (сүзтезмәләр) белән эшләгез. Җөмләдәге төп сүзләрнең астына сызыгыз. Бу җөмләгә (кисәккә) нинди мәгънә салынган?

3. Текстның идеясен (төп фикерен) формалаштырыгыз һәм авторның фикере сезнең позиция белән туры килүен-килмәвен билгеләгез.

4. Җөмләне (фрагментны) аңлатыгыз: сез аны ничек күрәсез, үз сүзләрегез белән аңлатып карагыз. Истә тотыгыз! Сез бу өзек турында үз фикерегезне белдерергә тиеш.

5. Тексттан үз фикерегезне дәлилли торган 2 мисал табыгыз. Шуны истә тотыгыз: сез өзек турында үз фикерегезне, бәягезне дәлиллисез.

6. Өзекнең мәгънәсен аңлату һәм үзегезнең нәтиҗә белән фикерегезне тәмамлагыз.

7. Структураны саклап, сочинение языгыз. Дөреслеген тикшерегез.

***Тезис формалаштырабыз.***

Сез тезиста бирелгән текст фрагментын аңлавыгызны күрсәтә белергә тиеш. Сочинениенең беренче өлеше күләме ягыннан зур булмаска мөмкин (1-2 җөмлә).

Сочинениенең башлам өлешенә мисаллар китерик.

**1 нче вариант**

*Минемчә, Ә.Еники әлеге юлларда икмәкнең кеше тормышындагы әһәмиятен күрсәтә. Әлбәттә, кайчак безнең икмәккә игътибарыбыз, хөрмәтебез җитеп кебек.*

**2 нче вариант**

*«Безнең беренче ризыгыбыз булган икмәккә кеше игътибары, кеше мәхәббәте кирәк. Бары шулчакта гына муллыкка ирешеп булачак», – дип язган Ә.Еники. Әйе, бу сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Минемчә, икмәк –*

*безнең тормышыбызның нигезе. Әлеге фикерне дәлилләү өчен текстка мөрәҗәгать итик.*

***Дәлил (аргумент) китерәбез.***

Аргумент – тезисны ачыклый торган дәлилләр (фактлар, мисаллар һ.б.). Тезистан аргументка **“Ни өчен?”** дигән сорау куеп була, аргумент исә **“Шуңа күрә…”, “Чөнки…”** дип җавап бирә.

Мәсәлән,

**Тезис:** Иртәнге аштан баш тартырга ярамый.

**Дәлилләр:**

1) Туклану организмга кирәк.

2) Ризык аша организм энергия ала.

Төп өлеш күләме ягыннан кереш һәм йомгактан артык булырга тиеш. Бу өлеш буенча күзәтелгән тупас хата – текстның эчтәлеген сөйләү һәм темага кагылышы булмаган дәлилләр китерү. Сочинениедә тезиста бирелгән фикерне үз сүзләрегез белән дөрес, нигезле итеп, логик рәвештә аңлата белүегез мөһим.

Димәк, дәлил китерү мисаллардан башка мөмкин түгел, шуңа күрә үзегезнең мисалларны текстның бәйләнешен һәм бөтенлеген сакларга тырышып кертергә кирәк. Моның өчен, гадәттә, 2 ысулны кулланалар: **өземтә китерү** һәм **җөмләнең тәртип номерын күрсәтү**.

Хәзер һәрбер ысулны конкрет карап китик.

**Өземтә китерү**

Өземтә китергәндә, берничә кагыйдәне истә тотарга кирәк.

1. Тулы өземтә куштырнаклар эченә алына һәм туры сөйләм кебек формалаштырыла:

| Тексттагы җөмлә | Өземтә |
|---|---|
| Тел ул – халыкның рухи дәвасы. *(М. Галиев)* | М.Галиев әлеге проблема турында болай дип әйтә: “Тел ул – халыкның рухи дәвасы”. |
| Халык – зур ул, көчле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. *(Г. Тукай)* | “Халык, – дип яза Г.Тукай, – зур ул, көчле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.” |

2. Әгәр өземтә кыскартылып бирелсә, төшереп калдырылган фикер урынына күпнокталар куела:

| Тексттагы җөмлә | Өземтә |
|---|---|
| Читтә тапкан бәхет – бер атналык тәхет кенә ул: бүген бар, иртәгә юк. Туган җирдә тамыр җибәрергә тиеш кеше. *(Р. Вәлиев)* | “Читтә тапкан бәхет... бүген бар, иртәгә юк. Туган җирдә тамыр җибәрергә тиеш кеше.” |

3. Өземтә сочинение язучының җөмләсенә мөһим компонент буларак кертеп җибәрелә ала. Бу очракта ул сүзләр куштырнаклар эченә алына һәм кечкенә хәрефтән языла.

| Тексттагы җөмлә | Өземтә |
|---|---|
| Китаплар – кешелекнең хәтере. *(Ф. Яруллин)* | Автор фикеренчә, “китаплар – кешелекнең хәтере”. |

4. Әгәр шигырьдән өземтә китерелсә һәм ул үзгәртелмәсә, куштырнаклар куелмый. Шигъри юллар сакланмаса, куштырнаклар кую мәҗбүри.

| **Тексттагы җөмлә** | **Өземтә** |
|---|---|
| Ана –<br>Бөек исем,<br>Нәрсә җитә ана булуга;<br>Хатыннарның бөтен матурлыгы,<br>Бөтен күрке ана булуда.<br>*(Һ. Такташ)* | Юкка гына Һади Такташ мондый юлларны язмагандыр:<br>Ана –<br>Бөек исем,<br>Нәрсә җитә ана булуга;<br>Хатыннарның бөтен матурлыгы,<br>Бөтен күрке ана булуда. |
| | Юкка гына Һ.Такташ болай дип язмагандыр: “Ана – Бөек исем, Нәрсә җитә ана булуга; Хатыннарның бөтен матурлыгы, Бөтен күрке ана булуда”. |

5. Өземтә китерүдә кыек сөйләм формасын да кулланып була.

| **Тексттагы җөмлә** | **Өземтә** |
|---|---|
| Шагыйрь – халык күңеленең барометры! *(Ш. Галиев)* | Ш. Галиев уйлавынча, шагыйрь – халык күңеленең барометры. |

Кирәгеннән артык өземтәләр белән мавыгырга киңәш итмибез, чөнки уку барышында фикерегезне аңлауда һәм сочинениене кабул итүдә авырлык туачак.

Алдан әйтеп үткәнчә, мисаллар китерүнең икенче ысулы – дәлил буларак бирелүче җөмләнең тәртип номерын күрсәтү. Еш кына укучылар аны дөрес күрсәтмиләр: җөмләнең номерын җәяләр эчендә бирәләр. Әлеге хатаны аңлатып үтик: тексттагы җөмләләрнең тәртибе җәяләр эчендә күрсәтелә, ләкин сочинениедә бу җәяләр күрсәтелми.

| **Хаталы вариант** | **Дөрес вариант** |
|---|---|
| (26) җөмлә белем алуның әһәмияте турында фикерләрне ассызыклый. | 1) 26 нчы җөмлә белем алуның әһәмияте турындагы фикерләрне ассызыклый.<br>2) Белем алуның әһәмияте 26 нчы җөмләдә аеруча ачык күренә. |

Караламада эшне башлаганчы, аерым биттә үзегез өчен терәк схема төзегез: өске өлешкә биремне, аның астына үзегезнең җавабыгызны (сорауга ни дәрәҗәдә туры килүенә игътибар итеп) язып куегыз. Сорауга җавапны **чөнки** теркәгеченнән башлап, дәлилләрне санап чыгыгыз.

Алга таба тезиста бирелгән фикерне төп өлештә дәвам итәбез. Сочинениенең төп өлешен язуга караган берничә үрнәк карап китик.

Дәлил өлеше:

*Беренчедән, икмәктә илнең, дәүләтнең бөтен куәте чагыла. Бары тик халкы тук, бәхетле булган дәүләт көнә*

*көчле, бай дәүләт булып санала. Без моны 10 нчы җөмлә мисалында күрә алабыз.*

*Икенчедән, икмәкнең һәрчак кадерле булган, чөнки кешелек тарихы төрле елларны күргән: уңыш начар булганда икмәкне бик кыйммәт бәягә читтән дә сатып алганнар. Бу фикерне раслау өчен 13 нче җөмләгә мөрәҗәгать итәбез.*

***Нәтиҗә ясыйбыз.***

Сочинениенең йомгагында, төп өлештә әйтелгән фикерләр гомумиләштерелеп, нәтиҗә ясала. Нәтиҗә тезис мәгънәсенә якын булырга тиеш. Язма эшегезне тикшергәндә, моңа игътибар итәргә кирәк.

Йомгаклауның берничә үрнәге белән танышыгыз.

1. Димәк, икмәктән башка безнең яшәешебезне күзалдына да китереп булмый. Һәркайсыбыз әлеге байлыкны кадерләп тотсын, акыл белән файдалансын иде.

2. Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, Ә.Еники бүгенге көндә аеруча мөһим булган теманы күтәрә. Дөрестән дә, бүгенге муллык заманында безнең икмәккә карата игътибарыбыз җитеп бетми.

3. Бу текст безне икмәккә карата игътибарлы булырга, аны кадерләп тотарга өйрәтә. Бу сыйфат исә безгә тормышта кирәк булачак.

Үрнәк өчен укучының сочинениесен (**21.1. биреме**) тәкъдим итәбез.

*«Безнең беренче ризыгыбыз булган икмәккә кеше игътибары, кеше мәхәббәте кирәк. Бары шул очракта гына муллыкка ирешеп булачак» – дип язган Ә.Еники. Мин*

*бу юлларны болай дип аңлыйм: икмәк – безнең байлыгыбыз, аннан башка без тормышыбызны күзалдына да китерә алмыйбыз, ә байлык турында һәрчак кайгыртып торырга кирәк. Әгәр дә без байлыкка битараф булсак яки уйламыйча туздырсак, без ул байлыкны бик тиз югалтыр идек. Бу сүзләремне тексттан мисаллар белән дәлилләп китәсем килә.*

*Беренчедән, икмәктә илнең, дәүләтнең бөтен куәте чагыла. Бары тик халкы тук, бәхетле булган дәүләт кенә көчле, бай дәүләт булып санала. Без моны 10 нчы җөмлә мисалында күрә алабыз.*

*Икенчедән, икмәкнең һәрчак кадерле булган, чөнки кешелек тарихы төрле елларны күргән: уңыш начар булганда икмәкне бик кыйммәт бәягә читтән дә сатып алганнар. Бу фикерне раслау өчен 13нче җөмләгә мөрәҗәгать итәбез.*

*Димәк, икмәктән башка безнең яшәешебезне күзалдына да китереп булмый. Һәркайсыбыз әлеге байлыкны кадерләп тотсын, акыл белән файдалансын иде*. (136 сүз)

**21.2.** биреме текстның эчтәлеге белән бәйле сүзнең мәгънәсен аңлатып сочинение язуны күзаллый. Ул түбәндәгечә бирелгән:

**21.2. ИКМӘК КАДЕРЕ** сүзләрен ничек аңлыйсыз? Үзегез формалаштырыгыз билгеләмәне дәлилләгез. Үзегез язган билгеләмәне тезис итеп алып, **«Икмәк кадере»** дигән темага сочинение языгыз. Тезисыгызны раслый торган 2

дәлил китерегез: дәлилнең берсен укылган тексттан алыгыз, икенчесен тормыш тәҗрибәсеннән чыгып формалаштырыгыз.

Биремнең үзе үк язу эзлеклелеген күрсәтә:

1) бирелгән сүзнең (сүзтезмә) мәгънәсен аңлатырга һәм шуннан чыгып билгеләмә формалаштыру;

2) үзегез формалаштырган тезика ике дәлил (берсе – укылган тексттан, икенчесе – тормыштан алынган) китерү;

3) эшне логик яктан дөрес итеп формалаштырырга һәм хатасыз язу;

4) сочинение текстын тикшереп чыгу.

Бу төр бирем буенча сочинение язганда түбәндәге конструкцияләрне файдаланырга була.

***Кереш өлештә:***

- ✓ *Бу төшенчәнең нәрсә белдергәнен аңлатырга тырышып карыйк.*
- ✓ *Бу төшенчәгә билгеләмә биреп карыйк.*
- ✓ *Минемчә, батырлык ул – ...*
- ✓ *Батырлык нәрсә ул? Әйдәгез шул турыда фикер йөртеп карыйк. Мин ... дип уйлыйм.*

***Төп өлештә:***

✓ *Бу төшенчәнең мәгънәсен тексттагы мисаллар ярдәмендә аңлатып була.*

✓ *Әйтелгәннәрне раслау өчен текстка мөрәҗәгать итик.*

✓ (Текстның авторы) *әсәрендәге өзектә минем фикеремнең (*тезисның яки төшенчәнең*) дөреслеген дәлилли торган мисалларны табарга мөмкин.*

- ✓ *... җөмләдә ... турында фикер раслана.*
- ✓ ... (биремдәге сүз-төшенчәне атыйбыз) *мисаллар тормышта да еш очрый.*
- ✓ *Фикеремне раслау өчен тормыштан* (әдәби әсәрдән, массакүләм матбугат чараларыннан һ.б.) *дәлил китерәсем килә.*

***Йомгаклау өлешендә:***

- ✓ *Шул рәвешле..., шулай итеп..., фикерне йомгаклап...,*
- ✓ *Формалаштырылган фикерне* (мисал-дәлилләр китерелгән чыганакларны атарга) *мисаллар белән дөрес итеп аңлатырга тырыштым.*
- ✓ *... турында фикерләрне анализлау барышында ... дигән нәтиҗәгә килдем.*

**21.2.** биреме буенча язылган сочинениенең дә үрнәгеннән бирәбез.

*Минемчә, икмәк кадере дигән сүз күпкырлы төшенчә. Ул үзенә бик күп әйберләрне сыйдыра: ачлык елларында кешеләрнең өзгәләнүләре дә, кеше хезмәте дә, басу-кырларда яткан бөртек тә...*

*Без икмәк белән көн саен очрашабыз һәм аннан башка бер генә көн дә тора алмыйбыз. Минемчә, бүгенге көндә безнең икмәккә игътибарыбыз җитеп бетми кебек. Еш кына урамда җирдә яткан икмәк сыныгы, хәтта бөтен икмәкне дә күрергә туры килә. Аяк астында яткан икмәк – кеше хезмәтен (игенче, пешекче) хөрмәт итмәү. Элеккеге заманда икмәккә карата бөтенләй башка*

*мөнәсәбәт булган. 19 нчы җөмләдә дә бу фикер ассызыклана.*

*Икмәк кадере турында әбиемнең сөйләгәннәре дә искә төшә. Ул чакта бер кисәк икмәк өчен кешеләр көннәр буе авыр хезмәт башкарган. Сугыш чоры һәм сугыштан соңгы елларда да икмәкнең бәясе бик югары булган.*

*Йомгаклап шуны әйтәсе килә, безнең төп ризыгыбыз булган икмәккә хөрмәтебезне киметмәсәк иде. Кешенең икмәккә мөнәсәбәте аның тәрбия дәрәҗәсенең күрсәтүче фактор икәнен дә онытмыйк.*

| **С өлешенә әзерләнү буенча белешмәлек** | |
|---|---|
| **Төп проблема (фикер)** | ● авторның уйлану объекты<br>● автор фикере<br>● аңа автор берничә мәртәбә әйләнеп кайта<br>● анда авторның позициясе ачык чагыла һ.б. |
| **Проблема (фикер) автор тарафыннан** | ● куела<br>● бәян ителә, аңлатыла<br>● карала<br>● күтәрелә<br>● искәртеп үтелә<br>● формалаштырыла<br>● анализлана<br>● чыгарыла<br>● тикшерелә һ.б. |
| **Автор ...** | ● укучыга эмоциональ яктан тәэсир ясый<br>● әһәмиятле, мөһим |

| | |
|---|---|
| | проблемаларны ассызлыклый<br>● укучыны ... чакыра<br>● күпчелек фикерен белдерә<br>● үз фикерен укучыга җиткерә һ.б. |
| **Сочинение темасы –** | ● яхшылык һәм начарлык<br>● табигатьне саклау<br>● тәрбия<br>● ялгызлык<br>● дуслык<br>● олыларга карата мөнәсәбәт һ.б. |
| **Нинди проблема күтәрелә?** | ● фәлсәфи<br>● әхлакый<br>● тормышчан<br>● сәяси<br>● милләтара<br>● мөһим<br>● көн кадагындагы һ.б. |
| **Проблема укучыны ... этәрә** | ● тирәтен уйларнырга<br>● фикер йөртергә<br>● үзеңнең ... мөнәсәбәтеңне яңадан карарга<br>● ... тирәнтен өйрәнә башларга<br>● теге яки бу мәсьәләгә башка күзлектән чыгып карарга<br>● үзеңнең фикерләрең белән уртаклашырга<br>● әйләнә-тирәдәгеләрне яхшырак аңларга һ.б. |
| **Сочинениедә әлеге** | ● битараф калырга ярамый |

| | |
|---|---|
| **сүзләр тезмәсен кулланырга мөмкин** | ● кызганычка каршы (бәхеткә каршы) ...<br>● авторның ... турындагы фикере кызыклы<br>● автор фикерен дәвам итеп, ... мәсьәләсенә тулырак тукталыйк<br>● бирелгән өзекнең мәгънәсен түбәндәгечә аңлыйм...<br>● минемчә, бу сүзләр .... булган мөнәсәбәтеңне яңача бәяләргә этәрә...<br>● әйтелгәнне раслау өчен<br>● ... нче җөмлә мисалында расларга мөмкин<br>● ... җөмлә ... турында фикерне раслый<br>● текстның авторы ... мөһимлегенә ышандыра<br>● әлеге проблеманы чишеп, автор ... нәтиҗәгә килә...<br>● шулай итеп, автор ... кебек җитди проблеманы күтәрә |

IX СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН
БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ТЕСТЫН
ҮТҮГӘ ӘЗЕРЛӘҮ

(ТЕКСТ БЕЛӘН ЭШЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ)

Форм.бум. 60х84 $^1/_{16}$. Гарнитура Times New Roman.
Усл.печ.л. 2,1
Оригинал-макет подготовлен в редакционно-издательском отделе
Института развития образования Республики Татарстан
420015 Казань, Б.Красная, 68
Тел.:(843)236-65-63 тел./факс (843)236-62-42
E-mail: irort2011@gmail.com